МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.12.2017 г.Казань № 909

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2018 елның 1 февралендә теркәлде, № 4553

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында" 2016 елның 21 июнендәге 348 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 7 июнендәге 116-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп, социаль, инженер һәм транспорт инфраструктуралары объектларының һәм күрсәтелүче хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керәчәк законнарның нигезләмәләрен үтәү максатында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында" 2016 елның 21 июнендәге 348 номерлы боерыгына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
2017 ел.30.12 № 909 боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында" 2016 елның 21 июнендәге 348 номерлы боерыгына
кертелә торган үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында" 2016 елның 21 июнендәге 348 номерлы боерыгында (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2017 елның 08 июнендәге 357 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) (алга таба – Боерык):

Боерык аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктуралары объектларының һәм социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүне дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында";

1 пунктта "дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру" сүзләреннән соң "һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктуралары объектларының һәм социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүне дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту буенча" сүзләрен өстәргә;

Боерык белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентында (алга таба – Административ регламент):

Административ регламент аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү

өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктуралары объектларының һәм социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүне дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламенты";

1 бүлектә:

1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1.1 Әлеге Административ регламент Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктуралары объектларының һәм социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүне дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тотканда (алга таба икесе бергә – төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)) административ процедураларының һәм административ гамәлләрынең чорларын һәм эзлеклелеген билгели.

Дәүләт функциясенең аталышы: Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктуралары объектларының һәм социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүне дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту (алга таба – дәүләт функциясе).";

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1.4. Дәүләт функциясе үтәлешен җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге:

"Россия Федерациясендә гражданнарны социаль яклау турында" 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 181-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 27.11.1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 294-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2008, № 52, 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында" 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2013, № 52, 7007 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләү турында" 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 99-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2011, № 19, 2716 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Персональ мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 152-ФЗ Федераль закон) (Россия

Федерациясенең законнар җыентыгы, 2006, № 31, 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында" 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 1999, № 14, 1650 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Азык-төлек продуктларының сыйфаты һәм куркынычсызлыгы турында" 2000 елның 2 гыйнварындагы 29-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2000, № 2, 150 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2006, № 19, 2060 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Сәламәтлек саклау өлкәсендә, мәгариф өлкәсендә һәм социаль өлкәдә үзләренә карата планлы тикшерүләр билгеләнгән ешлыкта үткәрелә торган юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек төрләре исемлеген раслау турында" 2009 елның 23 ноябрендәге 944 номерлы карары (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2009, № 48, 5824 ст.; 2011, №4, 614 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контрольлек органнары тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга ел саен планлы тикшерүләр үткәрү планнарын эшләү кагыйдәләрен раслау турында" 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең № 489 карары) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2010, № 28, 3706 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында" 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2015, № 19, 2825 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан документларга һәм (яисә) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә, шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга гарызнамәләр җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында" 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 323 номерлы карары) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2016 № 17, 2418 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүләр төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүләргә ризасызлыклар бирү һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында" 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2017, № 8, 1239 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә

дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контрольлек органнары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шушы документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан сорала һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлеген раслау турында" 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2016, № 18, 2647 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының "Социаль хезмәтләр күрсәтү турында шартнамәнең үрнәк рәвеше турында, шулай ук социаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым программасы рәвеше турында" 2014 елның 10 ноябрендәге 874н номерлы боерыгы (алга таба – Россия Хезмәт министрлыгының 874н номерлы боерыгы) (Российская газета, 2015, 12 гыйнвар, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында" Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында" 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының "СНиП 35-01-2001. Биналарның һәм корылмаларның авыр хәрәкәтләнүче халык төркемнәре өчен үтемлелеге" СП 59.13330.2016 кагыйдәләр җыелмасын раслау турында" 2016 елның 14 ноябрендәге 798/пр номерлы боерыгы белән расланган СНиП 35-01-2001. Биналарның һәм корылмаларның авыр хәрәкәтләнүче халык төркемнәре өчен үтемлелеге. СП 59.13330.2016 кагыйдәләр җыелмасы (алга таба – СП 59.13330.2016 кагыйдәләр җыелмасы) (Норматив, методик һәм типик проект документлары турында мәгълүмат бюллетене, № 2, 2017);

Россия Федерациясе Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Хезмәт, мәшгульлек һәм халыкны социаль яклау өлкәсендә инвалидларның һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуы шартларын тәэмин итү һәм шул ук вакытта аларга кирәкле ярдәмне күрсәтү тәртибен раслау турында" 2015 елның 30 июлендәге 527н номерлы боерыгы белән расланган Хезмәт, мәшгульлек һәм халыкны социаль яклау өлкәсендә инвалидларның һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуы шартларын тәэмин итү һәм шул ук вакытта аларга кирәкле ярдәмне күрсәтү тәртибе (алга таба – Россия Хезмәт министрлыгының 527н номерлы боерыгы белән расланган Тәртип) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы www.pravo.gov.ru, 2015, 18 сентябрь, бастырып чыгару номеры: 0001201509180024);

Россия Федерациясе Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Ияртеп йөрүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында" 2015 елның 22

июнендәге 386н номерлы боерыгы (алга таба – Россия Хезмәт министрлыгының 386н номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы www.pravo.gov.ru, 2015, 24 июль, бастырып чыгару номеры: 0001201507240003);

"Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында" 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 126-ТРЗ номерлы ТР Законы)(Республика Татарстан, 2014, 20 декабрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре" 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы" журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны оештыру тәртибен раслау турында" 2014 елның 25 ноябрендәге 909 номерлы карары ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы" журналы, 2014, № 93, 2872, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында" 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе (алга таба – ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе) ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы" журналы, 2015, № 23-24, 0785 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә социаль хезмәтләрне җиткерүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында" 2014 елның 31 декабрендәге 1101 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә социаль хезмәтләрне җиткерүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе (алга таба – ТР МК № 1101 карары белән расланган Ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе) ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы" журналы, 2015, № 34-35, 1171 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләрне

җиткерүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында" 2014 елның 29 декабрендәге 1053 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләрне җиткерүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе (алга таба – ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе) ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы" журналы, 2015, № 7-8, 0201 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында социаль хезмәтләрне җиткерүчеләр реестрын һәм алучылар регистрын формалаштыру һәм алып бару турында" 2014 елның 23 декабрендәге 1012 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр алучыларның регистрын формалаштыру һәм алып бару тәртибе (алга таба – ТР МК № 1012 карары белән расланган Регистр формалаштыру һәм алып бару тәртибе) ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы" журналы, 2015, № 3, 0093 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Социаль хезмәтләр күрсәткән өчен түләү күләмен һәм аны алу тәртибен раслау турында" 2014 елның 29 ноябрендәге 927 номерлы карары ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы" журналы, 2014, № 91-92, 2850 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

1.5 пунктында "(алга таба – социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр)" сүзләрен "социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче булып торган (алга таба – социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр), шул исәптән инвалидлар өчен социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең үтемле булуын тәэмин итүче," сүзләрен өстәргә;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1.6. Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләрнең үзләренең эшчәнлекләре барышында күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең күләменә, сыйфатына, аларны күрсәтү тәртибенә һәм шартларына карата, шулай ук инвалидлар өчен социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең үтемле булуын тәэмин итүгә карата 181-ФЗ номерлы Федераль законда, 442-ФЗ номерлы Федераль законда һәм аларга туры китереп кабул ителә торган Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән зарури таләпләрнең (алга таба – зарури таләпләр) үтәлүе, шулай ук Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан бирелгән күрсәтмәләрнең үтәлеше, гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә зыян китерүне туктату буенча, мондый зыян китерелү нәтиҗәләрен бетерү буенча чаралар уздыру төбәк дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) предметы булып тора.";

1.9 пунктында "социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә" сүзләрен төшереп

калдырырга;

1.9.1 пунктчасының тугызынчы абзацында "социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә" сүзләрен төшереп калдырырга;

1.11 пунктының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"РФ КоАП 9.13 статьясы, 19.5 статьясының 1 өлеше, 19.6, 19.7 статьялары күздә тоткан административ хокук бозулар турында беркетмә.";

2 бүлектә:

2.1.6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2.1.6. Әлеге Административ регламент турында белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәү буенча административ регламентларның бердәм реестрына һәм Татарстан Республикасында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлегенә кертелә, алар Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы рәсми сайтында урнаштырылган – http://mert.tatarstan.ru.";

2.4.2. пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) Министрлык вазыйфаи затының дәлилле йогынты акты, – юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә үткәрелгән контрольлек чаралары, гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан Министрлыкка килгән мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматларны карап тикшерү яки беренчел тикшерү нәтиҗәләрен анализлау нәтиҗәсендә, – түбәндәге фактлар турында:

- гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян килү куркынычы барлыкка килү;

- гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерү;

3 бүлектә:

3.1 пунктындагы 1 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1 таблица – Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләргә белдерелә торган зарури таләпләр исемлеге

| № п/п | Зарури таләпләр исемлеге | Зарури таләпне билгеле торган норматив хокукый акт | Тикшерү үткәргәндә юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан күрсәтелә торган документлар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Эшчәнлекне гамәлдәге норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашыру, шул исәптән лицензияле булу. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 1 пункты. ТР МК № 1100 карары белән | Социаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым программасында билгеләнгән социаль хезмәтләр күрсәтү өчен матди-техник |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.3.1 пункты.<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган Социаль хезмәтләр күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.3.1 пункты. | базаның, квалификацияле кадрларның булуын таныклый торган документлар (алга таба – ИППСУ). |
| 2. | Социаль хезмәт алучыларга социаль хезмәтләрне ИППСУ нигезендә һәм социаль хезмәт алучылар яисә № 442-ФЗ Федераль закон нигезендә аларның законлы вәкилләре белән төзелгән шартнамәләрнең шартларына туры китереп күрсәтү. | №442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 2 пункты, 16 статьясының 3 өлеше, 17 статьясы. | Социаль хезмәтләр күрсәтүгә шартанмәләр; ИППСУ буенча социаль хезмәт алучыларның формалаштырылган шәхси эшләре. |
| 3. | Ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 3 пункты, 21 статьясы. | Социаль хезмәт алучының гаризасы, ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтелү турында бу хезмәтләрне алучы һәм житкерүче турында, күрсәтелгән ашыгыч социаль хезмәтләрнең төрләре, вакытлары, датасы һәм аларны күрсәтү шартлары турында белешмәләре булган акт. Ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтелү турында акт. |
| 4. | Социаль хезмәт алучыларга яисә аларның законлы | № 442-ФЗ Федераль законның 12 | Социаль хезмәтләр белән тәэмин |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | вәкилләренә үтемле рәвештә бушлай нигездә аларның хокуклары һәм бурычлары турында, социаль хезмәт төрләре, аларны күрсәтү чорлары, тәртибе һәм шартлары турында, бу хезмәтләргә куелган тарифлар турында һәм социаль хезмәт алучы өчен аларның бәясе хакында яисә аларны бушлай нигездә алу мөмкинлеге турында мәгълүмат бирү. | статьясының 1 өлешендәге 4 пункты, 13 статьясы. | итүченең социаль хезмәт төрләре, аларны күрсәтү чорлары, тәртибе һәм шартлары турында, бу хезмәтләргә куелган тарифлар турында һәм социаль хезмәт алучы өчен аларның бәясе турында яисә аларны бушлай нигездә алу мөмкинлеге турында локаль актлары. |
| 5. | Персональ мәгълүматларны яклау турында Россия Федерациясенең персональ мәгълүматлар турындагы законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә социаль хезмәт алучылар турында мәгълүматтан файдалануга карата таләпләрне үтәү. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 5 пункты. № 152-ФЗ Федераль закон. | Социаль хезмәт алучыларның шәхси эшләре. |
| 6. | Татарстан Республикасында социаль хезмәт белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән социаль хезмәт җиткерүчеләр тарафыннан Татарстан Республикасында социаль хезмәт алучылар регистрын формалаштыру өчен мәгълүматларны Министрлыкка үз вакытында тапшыру. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 6 пункты, 26 статьясы. ТР МК № 1012 карары белән расланган Регистр формалаштыру һәм алып бару тәртибенең 5 пункты. | Социаль хезмәт алучыларның шәхси эшләре (социаль хезмәт алучылар регистрында социаль хезмәт алучылар турында мәгълүмат булу). |
| 7. | Ведомствоара хезмәттәшлек нигезендә балигълык яшенә җитмәгән балаларның ата-аналарын, опекуннарын, попечительләрен, бүтән законлы вәкилләрен кертеп, гражданнарны социаль күзәтүне, зарурлык булганда, медицина, психологик, | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 7 пункты, 22, 28 статьялары. | ИППСУ (социаль озата бару буенча аларда чагылдырылган чаралар белән) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | педагогик, юридик, социаль яисә бүтән характердагы, шул исәптән мондый ярдәмне күрсәтә торган оешмаларны җәлеп итеп, гамәлгә ашыру. | | |
| 8. | Зарурлык булган очракта социаль хезмәт алучыларга медик-социаль экспертиза буенча федераль учреждениеләр тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә уздырыла торган медик-социаль экспертиза (алга таба – МСЭ) узганда, шул исәптән инвалидлык группасы билгеләү, үзгәртү максатларында, яисә инвалидны тернәкләндерүнең хосусый программасын төзегәндә, гражданинга таныклау узуда булышлык күрсәтүне, МСЭ юллама алу максаты белән медицина оешмаларында медицина таныклавын узуда булышлык күрсәтүне тәэмин итү, МСЭ уздырыла торган урынга социаль хезмәт алучыны транспорт белән китерүдә ярдәм итү, тернәкләндерү буенча хосусый программаны тормышка ашыруда булышлык күрсәтү һ.б. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 8 пункты. | ИППСУ (МСЭ үтүдә шартлар тудыру буенча аларда чагылдырылган чаралар белән) |
| 9. | Социаль хезмәтләрне ышанычлы күрсәтү. | ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең1.3.2-1.3.4 пунктлары;<br>ТР МК № 1101 карары белән | Социаль хезмәтләр күрсәткәндә кулланыла торган җайланмаларның, материалларның ышанычлы булуы, нормаларга җавап бирүе турында документлар; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | расланган Ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.3.2-1.3.4 пунктлары;<br>ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 4.1 пункты. | социаль хезмәтләрне күрсәтү буенча кулланмалар, кагыйдәләр, технологияләр һәм методикалар; җитештерүдә контрольлек нәтиҗәләре, шул исәптән лаборатор тикшеренүләр һәм сынаулар үткәрү юлы белән. |
| 10. | Социаль хезмәтләрне сыйфатлы күрсәтү өчен кирәкле персонал булу | ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.4.1 пункты;<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган Ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.4.1 пункты;<br>ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 6.3.1 пункты. | Штат расписаниесе |
| 11. | Социаль хезмәтләр күрсәтүне туктатып торган яисә туктатканда нигезләрнең үтәлеше | ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.6 | Социаль хезмәт алучыларның шәхси эшләре. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | пункты;<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.6 пункты;<br>ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 4.6 пункты. | |
| 12. | Күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең сыйфаты билгеләнгән таләпләргә туры килү | ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.7 пункты;<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган Ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.7 пункты;<br>ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 6.4 пункты. | Социаль хезмәт алучыларның шәхси эшләре. |
| 13. | Социаль хезмәтләрне алучыларның шәхси әйберләре һәм кыйммәтләре саклануны тәэмин итү | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 12 | Социаль хезмәт алучыларның шәхси әйберләре һәм кыйммәтләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | пункты.<br>ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1 бүлеге;<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган Ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1 бүлеге;<br>ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 4.1 пункты. | саклануны тәэмин итү буенча локаль актлар |
| 14. | Социаль хезмәтләрнең билгеләнгән исемлеге һәм стандартлары нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү буенча таләпләр үтәлеше. | ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә 1 нче кушымта;<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган Ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә 1 нче кушымта;<br>ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр | Социаль хезмәтләр күрсәтүгә шартнамәләр;<br>Социаль хезмәт алучыларның шәхси эшләре. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | күрсәтү тәртибенең 1.3 пункты, кушымта | |
| 15. | Социаль хезмәтләр күрсәткән өчен түләү күләмен хисаплауның дөрес булуы өлешен тикшереп торудан кала, социаль хезмәтләрне түләү, өлешчә түләү яисә бушлай нигездә күрсәтү буенча таләпләрне үтәү | ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 2.2, 3.2, 4.2, 5.2, 6.2, 7.2 пунктлары;<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган Ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 2.2, 3.2, 4.2, 5.2 пунктлары;<br>ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 3.1-3.5 пунктлары | Социаль хезмәтләр күрсәтү турында шартнамәләр |
| 16. | Социаль хезмәтләр күрсәтүнең стационар һәм ярымстационар рәвешендә социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында хезмәтләр алганда социаль хезмәт алучыларга элемтә хезмәтләреннән, шул исәптән "Интернет" челтәреннән һәм почта элемтәсе хезмәтләреннән файдалану мөмкинлеге бирү | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 9 пункты | Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең локаль актлары |
| 17. | Социаль хезмәт күрсәтү оешмасында яшәүче ир белән хатынга изоляцияләнгән торак бүлмә бирү | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 10 пункты | Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең локаль актлары |
| 18. | Социаль хезмәт алучылар өчен | № 442-ФЗ | Социаль хезмәтләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | законлы вәкилләргә, адвокатларына, нотариусларга, иҗтимагый һәм (яисә) бүтән оешмалар вәкилләренә, руханиларга, шулай ук туганнарына һәм башка затларга көндезге һәм кичке вакытта алар янына иректе рәвештә килә алу мөмкинлеген тәэмин итү | Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 11 пункты | җиткерүченең локаль актлары. Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре |
| 19. | Инвалидлар белән эшләүче белгечләргә инвалидлар өчен, аларның организмында булган тотрыклы җитешсезлекләрен һәм яшәешенә бәйле чикләмәләрен исәпкә алып, объектларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләрдә инструктаж уздыру яисә укыту. | Россия Хезмәт министрлыгының 527н боерыгы белән расланган Тәртипнең 3 пункты | Инвалидлар белән эшләүче белгечләргә инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләрдә инструктаж уздыру яисә укыту журналы |
| 20. | Инвалидлар өчен объектларның үтемле булу дәрәҗәсен этаплап арттыру чараларын, объектларның һәм хезмәтләр күрсәтүнең инвалидлар өчен үтемле булу паспортлары булу-булмавын, мондый паспортларны алып баруга карата таләпләрнең үтәлүен билгеләү максатларында социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан объектларга тикшерү уздыру | Россия Хезмәт министрлыгының 527н боерыгы белән расланган Тәртипнең 9,10 пунктлары | Объектларның һәм хезмәтләр күрсәтүнең инвалидлар өчен үтемле булуы турында паспорт |
| 21. | Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуы өлешендә Россия Федерациясе | 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы;<br>419-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясы;<br>126-ТРЗ номерлы ТР Законы; | Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең локаль актлары;<br>объектның (бинаның, бүлмәнең һәм башка төрле корылманың) һәм анда күрсәтелә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | законнарында, Татарстан Республикасы законнарында каралган таләпләрнең, нормаларның һәм кагыйдәләрнең үтәлүен тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру:<br>социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларына, ял итү урыннарына һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә каршылыкларсыз үтеп керү өчен шартлар;<br>социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып;<br>күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча функцияләре тотрыклы бозылган инвалидларны озата бару һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларында аларга ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларның, аларның яшәеше буенча чикләмәләрен исәпкә алып, социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм хезмәтләр күрсәтүгә каршылыксыз үтеп керә алуын тәэмин итү өчен кирәкле мәгълүмат җайланмаларын һәм мәгълүмат җиткерү чараларын тиешенчә урнаштыру;<br>инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә | Россия Хезмәт министрлыгының 527н номерлы боерыгы белән расланган Тәртип;<br>Россия Хезмәт министрлыгының 386н номерлы боерыгы;<br>СП 59.13330.2016 кагыйдәләр җыелмасы | торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуы турында паспорт; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү; махсус өйрәтелгән булуын раслаучы һәм Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу буенча функцияләрне гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә торган формада һәм тәртиптә бирелә торган документы булганда, социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларына ияртеп йөрүче этне кертү; халыкка хезмәтләр күрсәтүче оешмаларда эшләүчеләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү | | |

4 бүлектә:

2 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2 таблица – Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге

| Тикшерү үткәрү өчен күрсәтелә торган документ | Документ рәвешен билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|

| | |
|---|---|
| 1. Юридик зат уставы | ГОСТ Р 53060-2008 "Халыкка социаль хезмәт күрсәтү. Социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре документлары" |
| 2. Җитәкчене вазыйфага билгеләү турында боерык, шулай ук социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең яисә вәкаләтле вәкиленең вәкаләтләрен билгеләүче документлар | Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 68 статьясы |
| 3. Социаль хезмәтләр күрсәтелү турында шартнамәләр | Россия Хезмәт министрлыгы боерыгына 1 нче кушымта<br>№ 874н |
| 4. Социаль хезмәт алучының шәхси эше | |
| 5. Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен билгеләү турында локаль акт | Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 189 статьясы |
| 6. Штат расписаниесе | ГОСТ Р 53060-2008 "Халыкка социаль хезмәт күрсәтү. Социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре документлары". № Т-3 унификацияләнгән форма, "Хезмәтне исәпкә алу һәм аның өчен түләү буенча беренчел исәпкә алу документларының унификацияләнгән формаларын раслау турында" 2004 елның 5 гыйнварындагы №1 РФ Госкомстат карары белән расланган. |
| 7. Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең социаль хезмәт төрләре, аларны күрсәтү чорлары, тәртибе һәм шартлары турында, бу хезмәтләргә куелган тарифлар турында һәм социаль хезмәт алучы өчен аларның бәясе турында яисә аларны бушлай нигездә алу мөмкинлеге турында локаль актлары | |
| 8. Социаль хезмәт алучыларның шәхси әйберләре һәм кыйммәтләре саклануны тәэмин итү буенча локаль акт | |
| 9. Объектның (бинаның, бүлмәнең | Россия Хезмәт министрлыгының 527н |

| | |
|---|---|
| һәм башка төрле корылманың) һәм анда күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуы турында паспорт | номерлы боерыгы белән расланган Тәртип |
| 10. Инвалидлар белән эшләүче белгечләргә инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләрдә инструктаж уздыру яисә укыту журналы | Россия Хезмәт министрлыгының 527н номерлы боерыгы белән расланган Тәртип"; |

5 бүлектә:

5.1 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 5.1.3.1 пунктчасын өстәргә:

"5.1.3.1. Дәүләт функциясен үтәгәндә шулай ук "Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын гамәлгә ашыру" административ процедурасы да гамәлгә ашырыла.";

5.2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.2.4. Еллык планны әзерләү буенча җаваплы башкаручы түбәндәге административ гамәлләрне гамәлгә ашыра:

- зарурлык булганда, билгеләнгән тәртиптә Федераль салым хезмәтеннән, шул исәптән электрон рәвештә, әлеге Административ регламентның 3 нче кушымтасына туры китереп, документларны һәм (яисә) мәгълүматларны сората һәм ала;

- билгеләнгән рәвештә еллык план проектын төзи;

- аны Бүлек башлыгы, министр белән килештерә;

Үтәү вакыты: планлы тикшерүләрне үткәргән елдан соң килүче елның 23 августыннан да соңга калмыйча;

- еллык план проектын карап тикшерү өчен үзләренә карата планлы тикшерүләрне үткәрү планлаштырылган социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләрнең тору урыны буенча прокуратура органына кәгазьдә (күчермәсен электрон рәвештә теркәп) кулга тапшыру турында хәбәрләмә белән почта аша заказлы хат итеп яисә "Электрон имза турында" 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза (алга таба – көчәйтелгән квалификацияле электрон имза) белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрә;

Үтәү вакыты: планлы тикшерүләрне үткәрү елыннан соң килүче елның 1 сентябренә кадәр.";

5.4.4.4 пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Җаваплы башкаручы тикшерүләрне оештырганда һәм уздырганда түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы белән расланган исемлеккә кертелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматларны шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының

яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 323 номерлы карарында билгеләнгән чорларда һәм тәртиптә сората һәм ала (әлеге Административ регламентка 3 нче кушымта).";

5.6.3.1 пунктчасында:

беренче абзацта "яисә РФ КоАП 19.6, 19.7 статьяларында каралган хокук бозуларны тикшерү барышында" сүзләрен "яисә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче тарафыннан планнан тыш тикшерү барышында РФ КоАП 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.4.1 статьясының 1 өлешендә каралган хокук бозуларның кылынуы, яки әлеге Административ регламентның 2.4.2 пунктындагы 2 һәм 3 пунктчаларда каралган нигезләрдә уздырыла торган планнан тыш тикшерү барышында РФ КоАП 9.13, 19.6, 19.7 статьяларында каралган хокук бозулар ачыклануы" сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"– административ хокук бозу турында эш кузгата – РФ КоАП 9.13 статьясында, 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.4.1 статьясының 1 өлешендә, 19.5 статьясының 1 өлешендә, 19.6 статьясынңа яисә 19.7 статьясында каралган, тиешенчә, административ хокук бозулар турында РФ КоАП күздә тоткан тәртипкә туры китереп, беркетмә төзи";

түбәндәге эчтәлекле 5.7 бүлекчә өстәргә:

"5.7. "Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын гамәлгә ашыру" административ процедурасы

5.7.1. Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары уздыруга бирем яисә әлеге Административ регламентның 2.4.6 пунктында күрсәтелгән очраклар административ процедураны уздыру өчен нигез булып тора.

5.7.2. Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан рәсми мәгълүмат системаларында, шул исәптән "Интернет" челтәрендә, социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр эшчәнлеге турында булган мәгълүматларны анализлау юлы белән зарури таләпләр үтәлүен күзәтү формасында гамәлгә ашырыла.

5.7.3. Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары министр (министр урынбасары) тарафыннан расланган бирем нигезендә гамәлгә ашырыла. Биремнең типик формасы Министрлык тарафыннан билгеләнә.

5.7.4. Биремдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) үзләренә карата социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары гамәлгә ашырыла торган социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр;

б) социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларының аталышы;

в) социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын гамәлгә ашыру өчен Министрлыктагы җаваплы вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, вазыйфалары;

г) социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын уздыру чоры;

д) социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр белән бәйләнешкә кермичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чаралары нәтиҗәләрен рәсмиләштерү чоры.

5.7.5. Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары нәтиҗәсендә күрсәтелгән чараларны уздыру өчен җаваплы булган вазыйфаи затлар биремдә билгеләнгән чорда социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары нәтиҗәләре турында Министрлык тарафыннан расланган формада хисап әзерлиләр.

Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын уздыру нәтиҗәләре турында хисап министр (министр урынбасары) тарафыннан раслана.

5.7.6. Әлеге Административ регламентның 2.4.2 пунктының 2 пунктчасына туры китереп, планнан тыш тикшерү уздыруга нигез булып торган зарури таләпләрне бозу очраклары билгеләнгән очракта, Министрлыкның вазыйфаи заты социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары нәтиҗәләрен анализлау нәтиҗәсе буенча дәлилле йогынты акты әзерли.";

Административ регламентка 1 нче кушымтада:

нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктуралары объектларының һәм социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүне дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 1 нче кушымта";

дәүләт функциясен үтәү буенча блок-схемада, "РФ КоАП 19.6, 19.7 статьялары күздә тоткан административ хокук бозу ачыкланган очракта, – административ хокук бозу турында беркетмә төзү" блогын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"РФ КоАП 9.13 статьясында, 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.4.1 статьясының 1 өлешендә, 19.5 статьясының 1 өлешендә, 19.6, 19.7 статьяларында каралган административ хокук бозу ачыкланган очракта, – административ хокук бозу турында беркетмә төзү".

Административ регламентка түбәндәге эчтәлекле 3 нче кушымта өстәргә:

"Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктуралары объектларының һәм социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең

инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүне дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 3 нче кушымта";

## ТИКШЕРҮЛӘР УЗДЫРГАНДА ВЕДОМСТВОАРА МӘГЪЛҮМАТИ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК КЫСАЛАРЫНДА МИНИСТРЛЫК ТАРАФЫННАН ДОКУМЕНТЛАР ҺӘМ (ЯИСӘ) МӘГЪЛҮМАТЛАР БЕЛӘН ЭШ ИТҮЧЕ БАШКА ДӘҮЛӘТ ОРГАННАРЫННАН, ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫННАН ЯИСӘ ОЕШМАЛАРДАН СОРАТЫЛА ТОРГАН ӘЛЕГЕ ДОКУМЕНТЛАРНЫҢ ҺӘМ (ЯИСӘ) МӘГЪЛҮМАТЛАРНЫҢ ИСЕМЛЕГЕ

| Соратыла торган документның аталышы һәм (яисә) соратыла торган мәгълүмат | Документлар һәм (яисә) соратыла торган мәгълүматлар белән эш итүче дәүләт органы |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр | Федераль салым хезмәте |
| Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр | Федераль салым хезмәте |
| Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрыннан белешмәләр | Федераль салым хезмәте |
| Медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бердәм лицензияләр реестрыннан белешмәләр ("Сколково" инновация үзәге территориясендә хосусый сәламәтлек саклау системасына керә торган медицина оешмалары һәм башка оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылучы күрсәтелгән эшчәнлектән тыш) | Росздравнадзор |
| Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез мөлкәт объекты турында өземтә | Росреестр |
| Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез мөлкәт объектына хокуклар күчүе турында өземтә | Росреестр". |